РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Какре-Елгинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Советская, д. 22, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, 423320,
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

Совет ур., 22 йорт, Азнакай районы, Кәкре Елга авылы, 423320
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «11» октябрь 2024 г.** **№ 2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елның 21 октябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларынан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Якты Юл торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю хезмәтләре өчен түләү,),

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, контракт буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, трубалар алмаштыру алмаштыр) Якты юл т. п;

ӘЙЕ КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 13 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 22 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Якты Юл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Якты Юл торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә

4. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 22 нче йорт адресы янашасендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: И.М.Мөхәмәтҗанов

КАКРЕ-ЕЛГИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ